КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.08.2019 г.Казань № 91-П

Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы, Раифа авылы адресы буенча урнашкан федераль әһәмияткә ия “Раифа монастыре корылмалары ансамбле, XVII – XVIII гасырлар” мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен раслау турында

“Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында”гы 2002 елның 25 июнендә кабул ителгән 73-ФЗ номерлы федераль закон, “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында”гы 2005 елның 1 апрелендә кабул ителгән 60-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, махсус җайга салына торган шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары буларак, федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объектларын һәм аларның территорияләрен саклауны һәм дәүләт тарафыннан саклап тотуны тәэмин итү максатларында, **боерам**:

1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы, Раифа авылы адресы буенча урнашкан федераль әһәмияткә ия “Раифа монастыре корылмалары ансамбле, XVII – XVIII гасырлар” мәдәни мирас объект ы территориясе чикләрен расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы, Раифа авылы адресы буенча урнашкан федераль әһәмияткә ия “Раифа монастыре корылмалары ансамбле, XVII – XVIII гасырлар” мәдәни мирас объекты территориясеннән файдалану режимын расларга (2 нче кушымта).

3. Боерыкның үтәлүен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының
2019 ел 21. 08 № 91-П
боерыгына 1нче кушымта

Татарстан Республикасы, Яшел Үзән районы, Раифа авылы адресы буенча урнашкан федераль әһәмияткә ия “Раифа монастыре корылмалары ансамбле, XVII-XVIII гасырлар” мәдәни мирас объекты территориясе **ЧИКЛӘРЕ**

Татарстан Республикасы, Яшел Үзән районы, Раифа авылы адресы буенча урнашкан федераль әһәмияткә ия “Раифа монастыре корылмалары ансамбле, XVII-XVIII гасырлар” мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең
**картасы (схемасы)**




Мәдәни мирас объектының топографик планы

Шартлы билгеләр:
- мәдәни мирас объекты территориясе чикләре
- борылыш нокталары

Татарстан Республикасы, Яшел Үзән районы, Раифа авылы адресы буенча урнашкан федераль әһәмияткә ия “Раифа монастыре корылмалары ансамбле, XVII-XVIII гасырлар” мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең
**картографик тасвирламасы**

Федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләре түбәндәгечә уза:

**көнбатыш өлеш:** монахлар корпусыннан көнбатыш дивар буйлап, казначылык корпусы фасадына һәм мунча бинасына параллель рәвештә төньяк манарага кадәр (1-3, 31-32 борылыш нокталары);

**төньяк өлеш**: төньяк манарадан дивар буйлап монахлар корпусына һәм София гыйбадәтханәсенә параллель рәвештә (3-11 борылыш нокталары);

**көнчыгыш өлеш**: монахлар корпусыннан дивар буйлап көньяк манарага кадәр (11-18 борылыш нокталары).

**көньяк өлеш**: көньяк манарадан дивар буйлап монахлар корпусына кадәр (18-31)

Татарстан Республикасы, Яшел Үзән районы, Раифа авылы адресы буенча урнашкан федераль әһәмияткә ия “Раифа монастыре корылмалары ансамбле, XVII-XVIII гасырлар” мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең
**борылыш нокталары**

| Нокта № | Нокта координатлары МСК 16 буенча | | Нокта координатлары 1984 елгы Бөтендөнья геодезия координатлар системасында (WGS 84) | |
|---|---|---|---|---|
| | X | Y | Киңлек, B | Озынлык, L |
| 1 | 488392.08 | 1280998.64 | 55°54'08.16N | 48°43'40.49E |
| 2 | 488394.48 | 1280999.43 | 55°54'08.24N | 48°43'40.54E |
| 3 | 488444.47 | 1281059.29 | 55°54'09.86N | 48°43'43.97E |
| 4 | 488448.07 | 1281058.18 | 55°54'09.98N | 48°43'43.91E |
| 5 | 488451.66 | 1281059.52 | 55°54'10.10N | 48°43'43.98E |
| 6 | 488452.99 | 1281064.28 | 55°54'10.14N | 48°43'44.26E |
| 7 | 488450.14 | 1281067.37 | 55°54'10.05N | 48°43'44.44E |
| 8 | 488446.37 | 1281067.70 | 55°54'09.93N | 48°43'44.46E |
| 9 | 488441.96 | 1281071.28 | 55°54'09.78N | 48°43'44.66E |
| 10 | 488418.07 | 1281106.64 | 55°54'09.02N | 48°43'46.70E |
| 11 | 488414.22 | 1281115.09 | 55°54'08.89N | 48°43'47.19E |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 12 | 488376.22 | 1281164.69 | 55°54'07.67N | 48°43'50.06E |
| 13 | 488362.36 | 1281180.54 | 55°54'07.23N | 48°43'50.97E |
| 14 | 488318.11 | 1281153.92 | 55°54'05.79N | 48°43'49.45E |
| 15 | 488314.55 | 1281160.19 | 55°54'05.68N | 48°43'49.81E |
| 16 | 488295.24 | 1281149.33 | 55°54'05.05N | 48°43'49.19E |
| 17 | 488300.21 | 1281140.89 | 55°54'05.21N | 48°43'48.70E |
| 18 | 488274.19 | 1281127.61 | 55°54'04.37N | 48°43'47.95E |
| 19 | 488271.86 | 1281129.86 | 55°54'04.29N | 48°43'48.08E |
| 20 | 488268.39 | 1281130.36 | 55°54'04.18N | 48°43'48.11E |
| 21 | 488265.03 | 1281128.60 | 55°54'04.07N | 48°43'48.01E |
| 22 | 488263.24 | 1281124.86 | 55°54'04.01N | 48°43'47.79E |
| 23 | 488264.68 | 1281120.48 | 55°54'04.06N | 48°43'47.54E |
| 24 | 488269.69 | 1281118.15 | 55°54'04.22N | 48°43'47.40E |
| 25 | 488302.56 | 1281067.39 | 55°54'05.28N | 48°43'44.47E |
| 26 | 488299.22 | 1281065.52 | 55°54'05.17N | 48°43'44.37E |
| 27 | 488305.40 | 1281054.08 | 55°54'05.37N | 48°43'43.71E |
| 28 | 488308.51 | 1281055.57 | 55°54'05.47N | 48°43'43.79E |
| 29 | 488340.55 | 1281014.71 | 55°54'06.50N | 48°43'41.43E |
| 30 | 488338.71 | 1281012.74 | 55°54'06.44N | 48°43'41.32E |
| 31 | 488346.00 | 1281004.29 | 55°54'06.67N | 48°43'40.83E |
| 32 | 488349.33 | 1281006.97 | 55°54'06.78N | 48°43'40.99E |

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының
2019 ел 21. 08 № 91-П
боерыгына 2нче кушымта

Татарстан Республикасы, Яшел Үзән районы, Раифа авылы адресы буенча урнашкан федераль әһәмияткә ия “Раифа монастыре корылмалары ансамбле, XVII-XVIII гасырлар” мәдәни мирас объекты территориясеннән
**файдалану режимы**

Татарстан Республикасы, Яшел Үзән районы, Раифа авылы адресы буенча урнашкан федераль әһәмияткә ия “Раифа монастыре корылмалары ансамбле, XVII-XVIII гасырлар” мәдәни мирас объекты территориясендә түбәндәгеләр **рөхсәт ителә:**

- мәдәни мирас объектларын саклау, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклап тоту өлкәсендә вәкаләтле җирле идарә органы тарафыннан бирелгән эшләрне башкаруга бирем һәм рөхсәт кәгазе, мәдәни мирас объектларын саклау, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклап тоту өлкәсендә вәкаләтле җирле идарә органы тарафыннан килештерелгән проект документациясе нигезендә, шулай ук мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә техник, авторлык күзәтчелеген һәм дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру шарты белән - мәдәни мирас объектын саклап калу буенча эшләр алып бару.

Мәдәни мирас объектын саклап калу буенча эшләр башкару объектның конструкция һәм башка ышанычлылык һәм иминлек характеристикаларына кагылган очракта, күрсәтелгән эшләр 2002 елның 25 июнендә кабул ителгән 73-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре)” Федераль законына (алда – Федераль закон) һәм Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексына яраклы рәвештә уздырыла.

- Федераль закон буенча каралган тәртиптә һәм очракларда эзләнү, проект, җир, мелиорация, хуҗалык һәм башка эшләр алып бару, шул исәптән:
- диссонанс объектларны юкка чыгару (соңрак төзелгән корылмалар);
- территорияне яшелләндерү һәм төзекләндерү, йорт яны хуҗалыгын алып бару;
- мәдәни мирас объектының бөтенлеген бозмый торган һәм аңа зарарлану, җимерелү яки юк итү, янгын куркынычы тудырмый торган юл һәм инженерлык коммуникацияләрен сузу һәм реконструкцияләү;
-археологик кыр эшләрен үткәрү;
- мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү таләпләренә каршы килми һәм хәзерге шартларда мәдәни мирас объектының эшләвен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган хуҗалык эшчәнлеген алып бару.

Татарстан Республикасы, Яшел Үзән районы, Раифа авылы адресы буенча урнашкан федераль әһәмияткә ия “Раифа монастыре корылмалары ансамбле, XVII-XVIII гасырлар” мәдәни мирас объекты территориясендә түбәндәгеләр **тыела** :

- капиталь объектлар төзү;
- мәдәни мирас объекты территориясендә булган капиталь төзелеш объектларының күләм-киңлек характеристикаларын зурайту;
- тарихи биләмәләр төзелеше эволюцион композициясенең традицион характеристикаларын бозу;
- мәдәни мирас объекты белән композицион рәвештә бәйле булган шәһәр һәм табигать ландшафты характеристикаларын үзгәртү.

Татарстан Республикасы, Яшел Үзән районы, Раифа авылы адресы буенча урнашкан федераль әһәмияткә ия “Раифа монастыре корылмалары ансамбле, XVII-XVIII гасырлар” мәдәни мирас объекты территориясендә түбәндәгеләр
**тәэмин ителә:**

-транспорт чаралары хәрәкәте мәдәни мирас объектының бөтенлегенә һәм саклыгына куркыныч янаган очракта, “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында”гы Татарстан Республикасының 2005 елның 1 апрелендә кабул ителгән 60-ЗРТ номерлы законы белән билгеләнгән тәртиптә транспорт чаралары хәрәкәтен тыю яки чикләү;

- мәдәни мирас объектын күрсәтү, төп ноктalardан һәм күзәтү мәйданчыкларыннан традицион визуаль кабул ителү мөмкинлеген тәэмин итү;

-янгын куркынычсызлыгы чараларын тормышка ашыру;

- экологик куркынычсызлык чараларын тормышка ашыру;
- мәдәни мирас объектын динамик тәэсирдән саклау.